ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

08.11.2019

№ 1655

2020 нче елга "Алабуга муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык - туган якны өйрәнү, экология - биология, хәрби - патриотик, социаль - педагогик, социаль - икътисадый, табигый - фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күпьюнәлешле өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 нче елның 29 нчы декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе законы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 нчы елның 31 нче декабрендәге «Балаларга туристик-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 939 нчы номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы белән туры китереп Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2020 нче елга түбәндәгеләрне расларга:

"Алабуга муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирүче күпьюнәлешле мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны, әлеге карарның 1 нче кушымтасында каралганча;

“Алабуга муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең өстәмә белем бирү дәүләт бюджет учреждениесендә балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларға өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарга карата төзәтү коэффициенты 0,5 күләмендә.

2. Алабуга муниципаль районының финанс-бюджет палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- әлеге карарның 1 нче пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренен норматив чыгымнары нигезендә Алабуга муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрен финанслауны;

- әлеге карарның 1 нче пунктында расланган Алабуга муниципаль районының Балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт законнары һәм башка норматив хокукый актлар белән билгеләнгән тәртиптә эш хакы индексы белән бер үк вакытта Алабуга муниципаль районының балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләренең норматив чыгымнарын яңадан карауны.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2020 нче елның 1 нче гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.М. Нуриев